| «Рассмотрена» | «Согласована» | «Утверждаю» |
| --- | --- | --- |
| Руководитель ШМО<br>_________ /______________ /<br>Протокол №____<br>от «___» _________ 20_ | Заместитель директора по УВР МБОУ «СМСОШ имени В.Ф.Тарасова»<br>_________ /______________ /<br>«___» _________ 20__г. | Директор МБОУ «СМСОШ имени В.Ф.Тарасова»<br>________ /______________ /<br>Приказ № ______<br>от «___» _________ 20__г. |

**Рабочая программа**
**по татарскому языку для 11 класса**

Муниципальное бюджетное общеобразовательное учреждение
«Старомокшинская средняя общеобразовательная школа
имени В.Ф.Тарасова» Аксубаевского муниципального района
Республики Татарстан

Мирзяновой Назии Сантбурхановны,
учителя татарского языка и литературы
первой квалификационной категории.

Рассмотрена и принята на заседании
педагогического совета.
Протокол № ___от ________ августа

Срок реализации: 2018-2019 учебный год

## АҢЛАТМА ЯЗУЫ

Эш программасы түбәндәге документлар нигезендә төзелде:

- Положением о рабочей программе учебных предметов , курсов МБОУ «Старомокшинская СОШ им.В.Ф.Тарасова» , утвержденным приказом от 29.08.2018 г. № 175

-Учебным планом МБОУ «Старомокшинская СОШ им.В.Ф.Тарасова» на 2018-2019 учебный год , утвержденным приказом от 29.08.2018 г № 168, календарным учебным графиком , утвержденным приказом от 29.08.2018 г №171

- Основной образовательной программы среднего общего образования МБОУ «Старомокшинская СОШ им.В.Ф.Тарасова»

Эш программасын тормышка ашыру өчен Россия Федерациясенең Мәгариф һәм Фән министрлыгы тарафыннан тәкъдим ителгән дәреслекләр исемлегендә түбәндәге дәреслек күрсәтелә: Р.З.Хәйдәрова, Р.Л.Малафеева Татар теле: 11 нче сыйныф рус телендә урта гомуми белем бирүче мәктәпнең (рус телендә сөйләшүче өчен), Казан, “Мәгариф” нәшрияты, 2010.

Елга 17 сәгать ( атнага 0, 5)

Фәнне өйрәтүнең **төп максаты – гамәли максат**: телне аралашу чарасы буларак үзләштерү өчен, укучыларга гаилә-көнкүрешкә, уку хезмәтенә бәйле сөйләм ситуацияләре кысаларында белем бирү һәм күнекмәләрен үстерү**. Гомуми белем бирү максаты** укучыларның акыл эшчәнлеген активлаштыру, логик фикерләү сәләтен камилләштерү, сөйләм культурасын үстерүдән гыйбарәт. **Тәрбияви максат** балаларның рухи дөньяларын баету, аларны татар халкының мәдәнияте һәм сәнгате белән таныштыру, төрле милләт вәкилләре арасында дуслык һәм хөрмәт хисе тәрбияләүгә юнәлтелә.

**Уку елы дәвамында формалаштырырга тиешле белем һәм күнекмәләр.**

Курс телдән һәм язмача аралашу темаларына бүлеп өйрәнелә.Программада сөйләмнең орфоэпик, интонацион, орфографик ягын, лексик ягын, грамматик ягын үзләштерүгә таләпләр куелган. Сөйләм эшчәнлеге төрләренә өйрәтүгә таләпләр төгәл һәм ачык билгеләнгән. 11 нче класста морфология, синтаксис өйрәнелә , грамматик категорияләр, материал тулыландырыла, кызыклы мәгълүматлар белән баетыла. Татар теленә өйрәткәндә предметара бәйләнеш әһәмиятле урын тота: география, тарих, рус теле һәм башка фәннәрне кулланып укыту дәресне эчтәлекле һәм мавыктыргыч итеп оештырырга мөмкинлек бирә.
Укучылар 11 нче класста татар сөйләмен тыңлап аңлау күнекмәләрен, диалогик һәм монологик сөйләм күнекмәләрен үстерү өстендә эшне дәвам итәләр; дөрес язу һәм язма сөйләм күнекмәләрен булдыру, татар теленең фонетик, орфоэпик, лексик, грамматик нигезләрен һәм үзенчәлекле тел күренешләрен гамәли үзләштерү өстендә эшлиләр.
Грамматикадан укучылар составы буенча җөмлә төрләрен ( бер составлы җөмлә төрләрен аера белү, төзи белү, кулланышка кертү), затланышлы, затланышсыз фигыльләрне аңлап аеру; тезмә фигыльләрне сөйләмгә кертү; сүз ясагыч кушымчалар ярдәмендә яңа исемнәр, рәвешләр ясау; сөйләмдә алмашлыкларның төрле төркемчәләрен дөрес куллану өстендә эшлиләр. Бәйлекләрнең төрле килештәге исемнәр белән кулланышын үзләштерәләр, бәйлек сүзләрне төрләндереп җөмләләр төзиләр.
Татар җөмләсендә сөйләм яңалыгының хәбәр алдында килүен, иярченле кушма җөмләләрнең аналитик һәм синтетик төрләрен аера, тыныш билгеләрен дөрес куя, бәйләүче чараларны куллана беләләр.

**УМК:** 1) Р.З.Хәйдәрова, Р.Л.Малафеева “Татар теле 11 класс” дәреслеге, Казан, “Мәгариф” нәшрияты, 2010 ел.
2) Р.З.Хәйдәрова, Р.Л.Малафеева, К.Г.Сәлимҗанова.Рус телендә сөйләшүче балаларга татар теле, уку дәресләре оештыру 11 сыйныф, Яр Чаллы, 2010 ел

**Белем дәрәҗәсенә таләпләр:**

1.Татар теленең төп фонетик үзенчәлекләрен гамәли белү.

2. Татар телендә сүз басымының үзенчәлекле очракларын белү һәм аерым грамматик формалардагы сүзләргә басымны дөрес куя белү.
3. Иҗек чигендәге фонетик үзгәрешләрне истә тотып сөйли алу: *кук-күге, кунак-кунагым, тап-таба, тек әле- /тэгәлэ/*

4. Татар сөйләмен синтагмаларга бүлә һәм логик басымның җөмләдәге урынын билгели белү.

5. Кушма, тезмә, парлы һәм кыскартылма сүзләрне дөрес куллана һәм яза белү.

6. Антоним, синоним, омонимнарны аера белү һәм сөйләмдә урынлы куллана алу.

7. Татарча-русча, русча-татарча һәм башка төрле сүзлекләрдән файдалана белү.

8. Лексик берәмлекләрнең күчерелмә мәгънәләрен,башкасүзләр белән бәйләнешкә керү үзенчәлекләрен белү.

9. Аерым сүз төркемнәренә хас грамматик формаларның татар һәм рус телләрендә тәңгәл килү-килмәвен белү.

10. Җөмләдә сүзләрне бәйләүче чараларны гамәли куллана белү.

11. Татар җөмләсендә сөйләм яңалыгының хәбәр алдында урнашуын белү. (*Бүген безгә **кунаклар** килә. Кунаклар безгә **бүген** килә. Кунаклар бүген **безгә** килә.)*

12. Иярченле кушма җөмләләрнең аналитик һәм синтетик төрләрен гамәли куллана белү.
13. Бер үк фикерне төрле синтаксик калыплар белән белдерә алу.

14. Язма сөйләмдә тыныш билгеләрен дөрес куя белү: ия белән хәбәр арасында сызык; җөмләнең аерымланган кисәкләре, модаль сүзләр, тиңдәш кисәкләр янында, кушма җөмләдә тыныш билгеләре (өтер, ике нокта, сызык ).

**Уку предметының төп эчтәлеге**

**Алда юллар, кайсын сайларга...** Югары уку йортлары һәм без сайлаган һөнәрләр, аларга куелган таләпләр. Бүгенге икътисади тормыштагы яңа һөнәрләр. Бүгенге мәктәптә мине борчыган проблемалар. БДИ, аңа әзерләнү.

**Татарстан Республикасы.** Татарстанның географик урыны, табигате. Хәзерге икътисад шартларында Татарстанның экономик, мәдәни һәм сәнгать казанышлары. Халыкара багланышлар. Халыклар дуслыгы. Татар теленең дөньякүләм урыны. Казанның тарихи һәм истәлекле урыннары. Татар халкының якты йолдызлары (композиторлар, рәссамнар,

җырчылар, артистлар, шагыйрьләр, язучылар). Күренекле шәхесләр турында кыскача белешмә бирә белү. Татарстанның бөтендөнья спорт үсешенә керткән өлеше. Татарстандагы яшьләр хәрәкәтләре**.**

**Беренче хисләр, гаиләдә мөнәсәбәтләр.** Дуслык һәм мәхәббәт, гаилә кору. Катнаш гаиләләр. Балаларны ярату, саклау. Ата-анага хөрмәт.

Эш программасын тормышка ашыру өчен Россия Федерациясенең Мәгариф һәм Фән министрлыгы тарафыннан тәкъдим ителгән дәреслекләр исемлегендә түбәндәге дәреслек күрсәтелә: Р.З.Хәйдәрова, Р.Л.Малафеева Татар теле: 11 нче сыйныф рус телендә урта гомуми белем бирүче мәктәпнең (рус телендә сөйләшүче өчен), Казан, “Мәгариф” нәшрияты, 2010.

## ТЕМАТИК ПЛАНЛАШТЫРУ

| Төп темалар | Укучыларның төп эшчәнлегенә характеристика | Сәгать саны |
|---|---|---|
| **Алда юллар, кайсын сайларга...** | һөнәр сайлауның җаваплылыгы турында әңгәмә кора белү. Яңа һөнәрләр, аларга хас сыйфатлар турында сөйләшү. БДИ, аңа яхшы әзерләнү һәм тапшыру өчен кирәкле сыйфатлар турында сөйләшү. Сайлаган югары уку йортлары турында сөйли белү. | **5** |
| **Татарстан Республикасы.** | Татарстанның географик урыны, табигате турында сөйләү.<br>Татарстанның экономик, мәдәни һәм сәнгать казанышлары турында сөйләшү.<br>Татарстанда яшәүче милләтләр, Татарстанның башкаласы – Казан шәһәре турында сөйли, музей-театрларын атый белү. Казан метрополитены турында сөйли белү.<br>Татар сәнгатенең күренекле вәкилләре турында кыскача белешмә бирү. | **6** |
| **Беренче хисләр, гаиләдә мөнәсәбәтләр.** | “Дуслык белән мәхәббәт” проблемалары буенча әңгәмә кора белү. Кызлар һәм егетләрнең мәхәббәткә карашлары турында фикер алышу. Билгеле план буенча дустың турында сөйли белү. Атаклы кешеләрнең мәхәббәт тарихлары турында сөйләшү.<br>Гаилә коруда, балалар тәрбияләүдә ата-ананың җаваплылыгы турында сөйләшү | **6** |
| **Барысы** | | **17** |

## ТЕМАТИК ПЛАН

| № | Дәреснең темасы | Сәг. саны |
|---|---|---|
| **Алда юллар, кайсын сайларга... (5 сәг.)** | | |
| 1. | Татар телендә авазлар. | 1 |
| 2. | Хикәя фигыльнең зат-сан белән төрләнеше. | 1 |
| 3. | **Резюме.** Бәйлекләр. | 1 |
| 4. | Зат алмашлыкларының килеш белән төрләнеше | 1 |
| 5. | Анкета. Сиңа нинди һөнәр туры килә? | 1 |
| **Татарстан Республикасы (6 сәг.)** | | |
| 6. | Сан, аның төркемчәләре, ясалышы ягыннан төрләре. | 1 |
| 7. | Бәйлек сүзләр. Бәйлек сүзләрне сөйләмдә дөрес куллану. | 1 |
| 8. | Кем нишли? | 1 |
| 9. | -чы, -че кушымчалары ярдәмендә исемнәр ясау | 1 |
| 10. | Татар телендә кушымчалар ялгану тәртибе. | 1 |
| 11. | Рәвеш төркемчәләре. | 1 |
| **Беренче хисләр, гаиләдә мөнәсәбәтләр (6 сәг.)** | | |
| 12. | Исем фигыль | 1 |
| 13. | Инфинитив. | 1 |
| 14. | Боерык фигыль. | 1 |
| 15. | Үткән заман хикәя фигыль формасы. | 1 |
| 16. | **Йомгаклау контроль эше.** | 1 |
| 17. | Рәсми кәгазьләр (автобиография, характеристика) | 1 |

*Кушымта*

## КАЛЕНДАРЬ-ТЕМАТИК ПЛАН

| № | Дәреснең темасы | Сәг. саны | Үткәрү вакыты: | |
|---|---|---|---|---|
| | | | План | Фактик |
| **Алда юллар, кайсын сайларга... (5 сәг.)** | | | | |
| 1. | Татар телендә авазлар. | 1 | 14. 01 | |
| 2. | Хикәя фигыльнең зат-сан белән төрләнеше. | 1 | 21. 01 | |
| 3. | **Резюме.** Бәйлекләр. | 1 | 28. 01 | |
| 4. | Зат алмашлыкларының килеш белән төрләнеше | 1 | 04. 02 | |
| 5. | Анкета. Сиңа нинди һөнәр туры килә? | 1 | 11. 02 | |
| **Татарстан Республикасы (6 сәг.)** | | | | |
| 6. | Сан, аның төркемчәләре, ясалышы ягыннан төрләре. | 1 | 18.02 | |
| 7. | Бәйлек сүзләр. Бәйлек сүзләрне сөйләмдә дөрес куллану. | 1 | 25. 02 | |
| 8. | Кем нишли?соравы. | 1 | 03. 03 | |
| 9. | -чы, -че кушымчалары ярдәмендә исемнәр ясау | 1 | 11. 03 | |
| 10. | Татар телендә кушымчалар ялгану тәртибе. | 1 | 18. 03 | |
| 11. | Рәвеш төркемчәләре. | 1 | 25.03 | |
| **Беренче хисләр, гаиләдә мөнәсәбәтләр (6 сәг.)** | | | | |
| 12. | Исем фигыль | 1 | 01.04 | |
| 13. | Инфинитив. | 1 | 08.04 | |
| 14. | Боерык фигыль. | 1 | 15.04 | |
| 15. | Үткән заман хикәя фигыль формасы. | 1 | 22.04 | |
| 16. | **Йомгаклау контроль эше.** | 1 | 29.04 | |
| 17. | Рәсми кәгазьләр (автобиография, характеристика) | 1 | 06.05 | |